| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**2016 елның 9 июне** | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 1506** |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 03 декабрендәге 2655 номерлы “Зеленодольск шәһәре, Карл Маркс урамы, 38 йорт адресы буенча урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын һәм җир кишәрлеген тартып алу турында” карары үз көчен югалтуын тану турында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 12 апрелендәге 877 номерлы «Зеленодольск муниципаль районының авария хәлендәге күпфатирлы йортлар исемлеген раслау турында» 2011 елның 31 декабрендәге 2425 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары нигезендә авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программадан ТР Зеленодольск шәһәре, Карл Маркс урамы, 38 йорт адресы чыгу уңаеннан, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 03 декабрендәге 2655 номерлы «Зеленодольск шәһәре, Карл Маркс урамы, 38 йорт адресы буенча урнашкан күчемсез мөлкәт объектларын һәм җир кишәрлеген тартып алу турында» карары үз көчен югалткан дип таныргa.
2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О. А. Матвеевага әлеге карарның күчермәсен:

-күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларны дәүләт теркәлүен башкаручы органга;

- «Зеленодольск муниципаль районының торак сәясәте департаменты» МКУна;

- торак биналар милекчеләренә җибәрергә.

3. ЗМР Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгы А. Н.Коршуновка әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында Зеленодольск муниципаль районының интернет челтәре сайтында һәм «Зеленодольская правда» газетасында урнаштыру юлы белән бастырып чыгаруны тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О. А. Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче А. Х. Сәхибуллин